# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:
а) 2 пунктны көчен югалткан дип танырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
"5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, бүтән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, шулай ук Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында сүз ирекe саклануга иҗтимагый контрольлек итүне гамәлгә ашыру.";

2) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"4) Иҗтимагый палата рәисен сайлау һәм вазыйфасыннан азат итү тәртибе, аның вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;
5) Иҗтимагый палата рәисе урынбасарларын сайлау һәм вазыйфаларыннан азат итү тәртибе, аларның вәкаләтләре, саны һәм эшчәнлек тәртибе;";

3) түбәндәге эчтәлекле 16[1] статья өстәргә:

"$16^{1}$ статья. **Иҗтимагый палата рәисе, аның урынбасарлары**

1. Иҗтимагый палата рәисе вазыйфасы буенча Иҗтимагый палата Советын җитәкли, Иҗтимагый палата, Иҗтимагый палата Советы, Иҗтимагый палатаның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыра, Иҗтимагый палата һәм Иҗтимагый палата Советы утырышларында рәислек итә, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, башка органнарда һәм оешмаларда Иҗтимагый палата исеменнән эш йөртә.

2. Иҗтимагый палата рәисе Иҗтимагый палата утырышында сайлана.

3. Иҗтимагый палата рәисе урынбасарлары Иҗтимагый палата рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый палата утырышында Иҗтимагый палата әгъзалары арасыннан сайланып куелалар һәм вазыйфаларыннан азат ителәләр.";

4) 17 статьядагы 3 –5 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 14 июле
№ 56-ТРЗ